КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 2 октябрь г.Казань № 1213

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасынраслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 21 июль, 522 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 11 июнь, 430 нчы; 2016 ел, 9 апрель, 210 нчы; 2016 ел, 21 ноябрь, 857 нче; 2017 ел, 17 февраль, 98 нче; 2017 ел, 19 октябрь, 797 нче; 2018 ел, 6 апрель, 211 нче; 2018 ел, 31 июль, 623 нче; 2018 ел, 3 декабрь, 1076 нчы; 2019 ел, 12 март, 178 нче; 2019 ел, 28 май, 446 нчы; 2019 ел, 12 ноябрь, 1033 нче; 2020 ел, 6 апрель, 256 нчы; 2020 ел, 22 июнь, 512 нче; 2021 ел, 30 июнь, 518 нче, 2022 ел, 31 март, 296 нчы; 2022 ел, 1 июль, 619 нчы; 2022 ел, 21 ноябрь, 1241 нче; 2023 ел, 4 апрель, 397 нче; 2023 ел, 19 июнь, 728 нче; 2023 ел, 10 август, 969 нчы; 2023 ел, 15 сентябрь, 1132 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын раслау турында»;

1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» Татарстан Республикасы дәүләт программасын (алга таба – дәүләт программасы) расларга.»;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитетын дәүләт программасының җаваплы башкаручысы итеп билгеләргә.»;

3 пунктта «Программа» сүзен «дәүләт программасы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасында туризм һәм кунакчыллык өлкәсен үстерү» дәүләт программасын яңа редакциядә (карарга теркәлә) бәян итәргә.

2. Бу карарның кушымтасында бирелгән исемлек нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларының кайбер нигезләмәләре үз көчен югалткан дип танырга.

3. Бу карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин